РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Школьная ул., д. 1, с. Алан, 422085
тел.: (84360) 54-1-13,
E-mail: Alan.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
АЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Мәктәп ур., 1 нче йорт, Алан авылы, 422085
тел.: (84360) 54-1-13,
E-mail: Alan.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053621 ОГРН 1061675010176 ИНН/КПП 1619004387/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 12** **15 май 2023 ел**

**Хайваннарны хуҗаларсыз кайтару тыела торган урыннарны билгеләү һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында**

«Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясенең 2023 елның 26 апрелендәге 409 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 елның 30 декабрендәге 1275 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегенең башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән, Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге чикләрендә хуҗалары булмаган килеш хайваннарны элекке яшәү урыннарына кайтару тыела торган урыннар исемлеген расларга.

2. Хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар итеп түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Б.Н. Хәсәнов

Теләче муниципаль районы
Алан авыл җирлеге Башкарма
комитетының «15»май 2023 ел
№ 12 карарына кушымта

Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге чикләрендә хайваннарны элекке яшәү урыннарына хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеге

Хайваннар өчен приютта стерилизация, билгеләү, исәпкә алу, карантин, дәвалау, вакцинация чаралары тәмамланганнан соң, башка хайваннарга яки кешегә карата мотивациясез агрессивлык күрсәтмәгән хуҗаларсыз хайваннарның элеккеге яшәү урыннарына (хайванны тоту башкарылган урын) кайтару тыела, әгәр дә мондый хайваннарны приютта, территориядә һәм территорияләрдән 500 метрдан якынрак ераклыкта тоту мөмкинлеге булмаса:

- социаль өлкә учреждениеләре территорияләре;
- сәламәтлек саклау объектлары территорияләре;
- мәгариф учреждениеләре территорияләре (мәктәпләр, балалар бакчалары);
- мәдәният объектлары территорияләре;
- балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары;
- иҗтимагый территорияләр (бакчалар, парклар, скверлар, урамнар, торак пунктлар мәйданнары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр полосалары);
- массакүләм чаралар уздыру өчен мәйданчыклар;
- стационар булмаган сәүдә объектларын, сәүдә нокталары территорияләрен урнаштыру урыннары;
-зиратлар һәм мемориаль зоналар.